| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2020 г.Зеленодольск № 40

Зеленодольск муниципаль районы шәһәр, авыл җирлекләре мөлкәтенә(шул исәптән җир кишәрлекләренә) ия булу, аннан файдалану, аның белән эш итү буенча, шәһәр, авыл җирлекләре мөлкәте объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен муниципаль берәмлекләрнең рәсми сайтларында бастырып чыгару буенча Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр, авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы « Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Зеленодольск муниципаль районы шәһәр, авыл җирлекләре мөлкәтенә (шул исәптән җир кишәрлекләренә) ия булу, алардан файдалану, алар белән эш итү буенча, муниципаль берәмлекләрнең рәсми сайтларында шәһәр, авыл җирлекләренең милек объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару буенча ,1 нче кушымта нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр, авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр, авыл җирлекләре Башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә тапшыру турында килешүләр төзергә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Күрсәтмәсе нигезендә, Әлеге карарның 1 пункты буенча, тапшырылган

вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына тапшырырга

4. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган финанс чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла, шулай ук «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс акчаларыннан өстәмә рәвештә файдаланырга хокуклы.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хүокукый мәгълүмат рәсми сайтында (htpp:/pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль**
**районы Башлыгы,**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**

1 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Советы карарына
2020 елның 29 декабре, № 40

**Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр җирлекләре исемлеге**

1. Васильево шәһәр тибындагы поселогы
2. Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы
3. Әйшә авыл җирлеге
4. Акъегет авыл җирлеге
5. Бишнә авыл җирлеге
6. Олы Ачасыр авыл җирлеге
7. Большие Ключи авыл җирлеге
8. Олы Карагуҗа авыл җирлеге
9. Олы Шырдан авыл җирлеге
10. Олы Җәке авыл җирлеге
11. Күгәй авыл җирлеге
12. Күгеш авыл җирлеге
13. Мамадыш Әкил авыл җирлеге
14. Мулла Иле авыл җирлеге
15. Түбән Урысбага авыл җирлеге
16. Новопольский авыл җирлеге
17. Норлат авыл җирлеге
18. Октябрь авыл җирлеге
19. Осиново авыл җирлеге
20. Раифа авыл җирлеге
21. Рус Әҗәле авыл җирлеге
22. Зөя авыл җирлеге
23. Өтәшкә авыл җирлеге

2 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Советы карары буенча
2020 елның 29 декабре, № 40

**Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында ___________ җирлеге Башкарма комитеты һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты арасында**
**КИЛЕШҮ №_____**

Зеленодольск ш. ___________

Зеленодольск муниципаль районының__________________ җирлеге Башкарма комитеты исеменнән, алга таба «Җирле Башкарма комитеты» дип аталачак, Устав нигезендә эш итүче __________________йөзендә, бер яктан һәм Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты исеменнән, алга таба «Район Башкарма комитеты» дип аталачак, Устав нигезендә эш итүче, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе _________________йөзендә, икенче яктан, икесе бергә «Яклар» дип аталучы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Зеленодольск муниципаль районының «_________җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм Зеленодольск муниципаль районы Уставына таянып түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

1. Әлеге Килешүнең предметы булып, әлеге килешүнең 1.1, 1.2 пунктларында күрсәтелгән, җирле Башкарма комитеты тарафыннан, җирлек мөлкәтенә, шул исәптән җир кишәрлекләренә, алга таба «Мөлкәт» дип аталучы, ия булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен район Башкарма комитетына тапшыру тора.

1.1. Мөлкәт белән идарә итү, аннан файдалану, алар белән эш итү буенча түбәндәге вәкаләтләр тапшырылырга тиеш:
а) муниципаль Мөлкәт реестрларын алып бару, Мөлкәтнең барлыгы һәм кулланылышы турында мәгълүмат;
б) милек хокукы яисә аренда шартнамәсен төзү хокукы булган, торгларда сату өчен тәкъдим ителә торган Мөлкәт исемлекләрен раслау;
в) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен тәкъдим ителә торган Мөлкәт исемлеген раслау;

г) читләштерелмәгән Мөлкәт исемлеген раслау;
д) Мөлкәтне арендага, милеккә тапшыру, түләүсез файдалануга, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, оператив идарә итүгә, хуҗалык алып баруга, файдалануның башка формаларынатапшыру турындагы карарлар кабул итү һәм документлар әзерләү хокукы;
е) муниципаль Мөлкәтне исәптән төшерү;
ж) муниципаль Мөлкәтне сату;
з) закон нигезендә сатучы функцияләрен гамәлгә ашыру;
и) «Россия Федерациясендә торак фондын хосусыйлаштыру турында» 1991 елның 4 июлендәге 1541-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә торак биналарны гражданнар милкенә тапшыру;
к) федераль милектәге, Татарстан Республикасы милкендәге, башка муниципаль берәмлекләрдәге Мөлкәтне муниципаль милеккә кабул итү;
л) муниципаль милектә булган Мөлкәтне федераль милеккә, Татарстан Республикасы милкенә, башка муниципаль берәмлекләргә тапшыру;
м) күчемсез милек объектларына хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органда күчемсез милек объектларына муниципаль милек хокукын теркәүне муниципаль берәмлек тарафыннан гамәлгә ашыру өчен документлар әзерләү;
н) хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларына һәм коммерциягә карамаган оешмаларга кертем сыйфатында Мөлкәт кертү;
о) Мөлкәтне залогка тапшыру һәм тапшыруны килештерү;
п) Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган , Мөлкәт белән идарә итү, аннан файдалану, эш итү буенча башка вәкаләтләре.

1.2. Муниципаль берәмлекләрнең рәсми сайтларында җирлек Мөлкәте объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән Мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару вәкаләтләре тапшырылырга тиеш.

## 2. ЯКЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1 Җирле Башкарма комитеты түбәндәгеләргә бурычлы:

- әлеге Килешүгә кул куелганнан соң, биш көн эчендә, җирлекнең муниципаль милкендәге Мөлкәт объектлары реестрларын тапшырырга ;
- 1 бүлектә күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәк булган бюджетара трансфертлар рәвешендә финанс чараларын тапшырырга (алга таба-тапшырылган вәкаләтләр);
- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны бирергә;
- район Башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне башкарганда консультатив һәм методик ярдәм күрсәтү.

2.2 Җирле Башкарма комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

- район Башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен, шулай ук әлеге килешүнең 3 бүлегендә күрсәтелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны контрольдә тотарга. Кагыйдә бозулар

ачыкланган очракта, район Башкарма комитеты тарафыннан үтәлүе мәҗбүри булган , ачыкланган хокук бозуларны бетерү өчен, хәбәр итү вакытыннан алып билгеле бер вакытта, язма таләпләр җибәрергә;

- район Башкарма комитетыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шулай ук әлеге максатларга бирелгән финанс чараларын куллану белән бәйле кирәкле мәгълүматны, материалларны һәм документларны соратып алырга;

- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча район Башкарма комитетына тәкъдимнәр кертү;

-районның җирле үзидарә органнарына, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле матди ресурсларны, килешү имзаланган көннән алып утыз көн эчендә , түләүсез файдалану шартнамәсе буенча тапшырырга.

2.3 Район Башкарма комитеты түбәндәгеләргә бурычлы:

- тапшырылган вәкаләтләрнең тиешле дәрәҗәдә үтәлешен законнар таләпләре нигезендә, шул исәптән җирле Башкарма комитеты тарафыннан бары тик тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга гына бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны гамәлгә ашырырга (тәэмин итәргә);

- җирле Башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турындагы язма таләпләрне бер айдан да соңга калмыйча карап тикшерү (әгәр дә таләптә башка срок күрсәтелмәсә), җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрү һәм бу хакта җирле Башкарма комитетына кичекмәстән хәбәр итү;

- килешүнең гамәлдә булуы туктатылган очракта, файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтарырга;

- тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә үтәү мөмкин булмаган очракта, вәкаләтләрне үтәү мөмкинлеге булмау турында билгеле булган вакыттан алып ун көн эчендә, җирле Башкарма комитетына язма рәвештә хәбәр итәргә.

2.4 Район Башкарма комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен, җирле Башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын алу һәм алардан файдалану;

- җирлек Башкарма комитетыннан, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен, кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә матди ресурслардан һәм башка финанс чараларыннан законнар нигезендә файдалану;

- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән, гамәлдәге законнарга каршы килми торган, теләсә нинди башка гамәлләр кылырга.

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе нигезендә, Әлеге Килешүнең 1.1, 1.2 п. каралган вәкаләтләрне «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә башкарма-күрсәтмә органнарына җибәрергә.

## 3. БЮДЖЕТАРА ТРАНСФЕРТЛАРНЫҢ ЕЛЛЫК КҮЛӘМЕН БИЛГЕЛӘҮ ТӘРТИБЕ ҺӘМ АНЫ КҮЧЕРҮ СРОКЛАРЫ

3.1. Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру ел саен Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан бюджет законнары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә гамәлгә ашырыла.

3.2. Яклар ел саен, әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымта нигезендә, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен билгели.

3.3. Район Башкарма комитеты тарафыннан бюджетара трансфертларны максатчан файдаланмаган очракта, алар җирле Башкарма комитеты таләбе буенча, ун көн эчендә, җирле бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

3.4. Бюджетара трансфертлар авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан ай саен, агымдагы елның 10 числосына кадәр, бюджетара трансфертлар күләменең 1/12 күләмендә күчерелә.

## 4. ВӘКАЛӘТЛӘРНЕҢ ҮТӘЛЕШЕН ТИКШЕРҮ

4.1. Җирле Башкарма комитеты тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, җирле Башкарма комитетының мотивлаштырылган соравы буенча тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында район Башкарма комитетыннан мәгълүмат соратып ала.

4.2. Район Башкарма комитеты ел саен, агымдагы елның 31 декабренә кадәр, вәкаләтләрнең үтәлеше, вәкаләтләрне үтәү өчен бирелгән финанс чараларыннан файдалану, шулай ук аерым соратулар буенча әлеге Килешү предметына кагылышлы башка мәгълүмат җибәрә.

4.3. Бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны гамәлдәге законнары нигезендә җирлекнең Башкарма комитеты, муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыручы орган башкара.

## 5. КИЛЕШҮНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУ ВАКЫТЫ

5.1. Әлеге Килешү басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

5.2. Әгәр Якларның берсе дә, әлеге Килешүнең гамәлдә булу вакыты чыкканчы бер ай кала, Килешүне өзү нияте турында икенче Якка хәбәр итмәсә, ул 5 елга озайтылган дип санала.

## 6. КИЛЕШҮНЕҢ НИГЕЗЛӘРЕ ҺӘМ ГАМӘЛДӘ БУЛУЫН ТУКТАТУ ТӘРТИБЕ

6.1. Килешү, Якларның Килешүендә башкасы каралган очраклардан тыш, срок үткәннән соң гамәлдә булуын туктата.

6.2. Әлеге Килешүнең түбәндәге очракларда гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

- Яклар килешүе буенча.

-түбәндәге очракларда берьяклы тәртиптә:

- Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарын үзгәртү нәтиҗәсендә район Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне башкару мөмкин булмаса, йә килеп туган шартларда әлеге вәкаләтләр җирле Башкарма комитеты тарафыннан аеруча нәтиҗәле гамәлгә ашырылырга мөмкин;

- әлеге килешү нигезендә якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәве яки тиешенчә үтәмәве.

6.3. Әлеге Килешүне өзү турында хәбәрнамә язма рәвештә җибәрелә. Килешү, күрсәтелгән хәбәрнамәне җибәрү датасыннан 30 көн узгач, өзелгән дип санала.

6.4. Әлеге килешүнең гамәлдә булу срогыннан алда туктатылган очракта, район Башкарма комитеты вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән, файдаланылмаган финанс чараларын җирлек Башкарма комитетына кире кайтара.

## 7. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

7.1. Яклар Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Килешү нигезендә, әлеге Килешүдә каралган бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җавап тоталар

7.2. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

## 8. КИЛЕШҮНЕ ҮТӘМӘГӘН ӨЧЕН ФИНАНС САНКЦИЯЛӘРЕ

8.1. Әлеге Килешү буенча Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен, гаепле Як икенче Якка, әлеге килешүгә кушымтада каралган, финанс чаралары күләменең 0,1%ы күләмендә штраф түли.

8.2. Штраф түләү Якларны әлеге килешү буенча йөкләмәләрне алга таба үтәүдән азат итми.

## 9. БӘХӘСЛӘРНЕ ХӘЛ ИТҮ ТӘРТИБЕ

9.1. Әлеге Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле бәхәсләр, Якларның сөйләшүләр алып бару һәм башка килештерү процедураларын куллану юлы белән хәл ителә.

9.2. Бәхәсне сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедураларыннан файдалану юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнар нигезендә суд тәртибендә каралырга тиеш.

## 10. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

10.1. Әлеге Килешүгә кертелгән барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

10.2. Әлеге Килешүдә җайга салынмаган мәсьәләләр буенча Яклар гамәлдәге законнарга таяна.

10.3. Чираттагы финанс елының 1 гыйнварына кулланылмаган башка бюджетара трансфертлар РФ БК 242 статьясы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге (шәһәр, авыл җирлеге) бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

10.4. Тигез юридик көчкә ия булган әлеге Килешү ике (ике) нөсхәдә, һәр як өчен бер нөсхәдә, төзелде.

10.5. Әлеге Килешүгә кушымта итеп бирелә:

«Бюджетара трансфертлар күләме» кушымтасы.

## 11. ЯКЛАРНЫҢ ИМЗАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Зеленодольск муниципаль районы<br>______________________________<br>җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе | Татарстан Республикасы<br>Зеленодольск муниципаль районы<br>Башкарма комитеты җитәкчесе |
| ____________/__________ ____/ | ____________/ _______________/ |
| «____» _____________20____ел | «____» ____________20__ел |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм _________________ җирлеге Башкарма комитеты арасында мөлкәткә (шул исәптән җир кишәрлекләренә) ия булу, аннан файдалану, аның белән эш итү буенча, муниципаль берәмлекләрнең рәсми сайтларында шәһәр, авыл җирлекләре мөлкәтләре объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тапшыру турында килешүгә кушымта

**Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме**

Әлеге Килешүнең предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру ел саен Зеленодольск муниципаль районының __________________ җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән башкарыла. Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме ___________ сум тәшкил итә.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Зеленодольск муниципаль районы<br>________________________<br>җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе<br>___________/___________<br>____/<br>«____»_____________20_<br>___ел | Татарстан Республикасы<br>Зеленодольск муниципаль районы<br>Башкарма комитеты җитәкчесе<br>___________/ ______________/<br>«____» ____________20__ел |